ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 8 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасы медицина оешмаларын» сүзләрен «1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына ведомство буйсынуындагы оешмаларны» сүзләренә алмаштырырга, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» сүзләрен «күрсәтелгән органга ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» сүзләрен «сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең

вәкаләтле органына ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмаларына» сүзләрен «сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына ведомство буйсынуындагы оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлешне өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезләмәләре Россия Федерациясенең норматив хокукый акты белән дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Россия Федерациясе субъектының закон акты нигезендә бердәнбер тәэмин итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән очракта кулланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 20 июнь
№ 50-ТРЗ